# Татарстан яшьләре

№13

(8813)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

29 июль, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *



## "Кешесен күрсәтсәләр, бәреп үтерер идем"

**Әгәр Русиядә сәяси мәдәният дигән нәрсәнең "с" хәрефе генә булса да, хөкүмәт бу кадәр кылана алмас иде. Үз халкын шулкадәр мыскыллаган тагын бер шундый дәүләтне эзләп карарга кирәк әле. Ә халык нәрсә ди? Шушы сорауга җавап эзләп "Т.Я." урамга, банк янындагы чиратлар ягына юл тотты. Андагы мәхшәрне бер фоторәсем белән генә күрсәтеп булмый, шулай да М.Шакирҗановның бу фотосы хәлне бераз күзалларга мөмкинлек бирә. Без барлык кешеләргә дә бер үк сорау бирдек: "Хөкүмәтнең соңгы гамәленә ни әйтерсез?"**

***Рәшидә ханым (бухгалтер):***

- Әгәр хөкүмәттә шушыларны болгатып ятучы кешене күрсәтсәләр, бүтәннәр рәхәт яшәсен өчен, билләһи, үземне кызганмас идем, барып бәреп үтерер идем шуны!

***Фатих бабай:***

- Ни әйтергә дә белгән юк инде. Хөкүмәт башында утыргач, укыган кешеләрдер инде алар. Ләкин барыбер болай эшләмәскә кирәк иде. Әзрәк уйларга була ич инде.

***Зәйнәп апа (лаеклы ялда):***

- Үлемтеккә дип җыйган акчаларны бер алыштырып интеккән идек инде. Яңалары җыелган иде. Менә хәзер шулар белән тинтерәп йөреш.

***Габделхак (эшче):***

- Ничектер шулай килеп чыкты инде, бу каһәр суккан акча реформасы безнең гаиләнең акчасы аз вакытына туры килде. Һибары мең ярым бар иде, җитмәсә, шулар барысы да иске акча белән булып чыкты. Кибеттә аңа берни бирмиләр, ә ашыйсы килә бит. Менә, аптырап килдем инде алыштырырга. Ләкин бүген эш барып чыгармы икән, белмим?!

***Раушания (Үзбәкстан кунагы):***

- Казанга бер туганымны шифаханәгә алып килгән идем. Юлга чыкканда буш кул белән китмисең инде ул. Акча алышыну турында ишеткәч, янчыгымны ачып карасам, бөтенесе иске акча. Нишлим инде мин хәзер? Ничек ул кадәр акчаны алыштырып бетермәк кирәк? Кунакханәгә дә урнашмаган әле. Нишли бу хөкүмәт,ә?

## Халык соравы буенча

Татарстан хөкүмәтенең акча алыштыруга карата чыгарылган карарын әнә шулай дип атарга мөмкин булыр иде. Әмма анда рәнҗетелгән һәм мәсхәрәләнгән халыкның хәлен җиңеләйтү буенча әллә нинди чаралар күренми. Шулай да баштан сыйпарга, юатырга маташкан хөкүмәт чараларын әйтеп үтәбез.

Беренчесе эш урыннарында "өчлек"ләр төзелә. Алар үзләрендә эшләүчеләрнең акчасын алыштыру белән шөгыльләнә.

Икенчесе банк бүлекчәләренең эш вакыты иртәнге 8 дән кичке 8 гә кадәр озайтыла.

Ә "банкларны яңа акчалар белән тәэмин итәргә" ише гомуми сүзләргә килгәндә, алар бүген үтәлми. Кибетләрдә акча кайтарып бирү дигән нәрсә онытылып бара - йә юк диләр, йә өстәп тоз, кәнфит, шырпы, йомырка (кайда нәрсә бар) ише товарлар бирелә. Билгеле, монда төгәллек турында сүзнең булуы да мөмкин түгел.

Русия президенты үз халкын "яклау чараларын" игълан итте. Аннан күренгәнчә, акча алыштыру күләме 100 мең сумга җиткерелә, ә 1,3,5 һәм 10 сумлык акчалар август азагына кадәр кулланышта кала. 10 мең сумлык иске акчаларны алыштыру күләме чикләнмәгән.

## Татарстанга үз акчасын булдырырга вакыт җитте

Грузиядә урысның агач "рубеле" чит ил валютасы дип игълан ителде.

Кыргызстан сомының Русия сумына чагыштырмасы беренчесе файдасына ике мәртәбә үсте. Президент Акаевның ике ай элек, Кыргызстанның үз валютасын керткән чакта әйткән: "Ике айга сусзах, соңга калачакбыз", - дигән сүзләрен искә төшереп сөенделәр.

Кибетләрдә кайтарып бирергә вак акча юк, аның урынына шырпы һәм кәнфит йөри. Шул ук вакытта банклар үзләрендә таңкә акчалар күпләп җыелуы турында белдерә һәм кибетләрнең аларны алырга теләмәүләрен әйтә. Кибетчеләр, үз чиратларында, банкны вак акча белән тәэмин итмәүдә гаеплиләр.

Көнбатыш матбугаты Русиядә диктатура урнашырга уңай шартлар тууы турында хәбәр итә.

Кыскасы, шайтан үзе аягын сындырырлык хәбәри чытырманлык башланды. Шулай да, дөньядан килгән хәбәрләрне араларга һәм аларны анализларга тырышып карыйк әле.

Күзгә бәрелеп торган беренче факт шул: Русиядәге акча реформасы бу илдә генә түгел, бөтен дөньядагы хәлне шартлатты. "Элеккеге" СССРның союздаш республикалары пошаманга кала төште. Чөнки "бердәм сум зонасы" турындагы сүзләрнең бушлыкта эленеп калуын аңлау өчен хәзер әллә ни тирәннән уйлый белергә кирәкми. Үз валюталарын булдырган республикалар исә, эчтән генә сөенә, чөнки алар акчаларының дәрәҗәсе югарыга үрмәли башлады.

Сүз дә юк, бу реформа кемгәдер ни өчендер кирәк. Бәлки бераз вакыт үткәннән соң Павловның 50 һәм 100 сумлыклар белән ясаган аферасы ачылган кебек, бу җинаятькә охшаш гамәл дә гаепләнер әле. Миңа калса, бу очракта "акча реформасы"на кагылышлы ике генә нәтиҗә ясарга була.

Беренчесе. Бу эшне үздыру ниндидер катламга зур акчалар эшләү өчен кирәк булган.

Икенчесе. Монысын бераз тәфсилләбрәк аңлатмый булмас. Якынча туксанынчы елдан башлап Русиядә анархия хөкем сөрә. Теләгән хакимдар, бу кадәр вакыт эчендә, ил нинди генә иләмсез зур булмасын, тәртип урнаштыра ала иде. Бу хәл, белгәнегезчә, булмады һәм булуы көтелми дә. Димәк, теләмиләр. Кинәт кенә бер-бер артлы туа башлаган республикаларны искә төшерсәң, үзеннән-үзе нәтиҗә килеп чыга. Русия дигән илнең таркалуы урыс булмаган милләтчеләргә генә кирәкми. Русия җитәкчелеге сүздә "бербөтен һәм бүленмәс" турында сөйләсә дә, гамәлләре шуның нәкъ киресе. Күрәсең, Татарстан җитәкчелеге дә моны аңламый түгел, аңлыйдыр һәм, күрәсең, илебезнең суверенитетын ныгыту юлында чираттагы кыю адымнарны ясарга вакыт җиткәндер. Шундый адымнарның берсе - үз акчабызны Татарстан эчендә әйләнешкә кертү була алыр иде.

**Равил САБЫР.**




***Симферопольдә*** *27 июль көнне кырым татар халкының II Корылтае башланды. Аның эшендә 275 делегат катнаша. Кырымда безнең кардәшләрне кысу әле һаман да дәвам итә. Корылтай үз эшен башласа да, Кырымның ЮСы аны конституциядән тыш орган дип белдерде.*

***Литваның*** *Апитус шәһәре мэры автобус станциясендә һәм базарда урнашкан бәдрәфләрне реконструкцияләү турында АКШ фирмасы белән килешү төзеде. Аның буенча, бәдрәфләр модалы салоннарга әверелергә тиеш. Аларда йоклап та булачак.*

***Чаллының*** *югары лигада уйнаучы "КамАЗ" футбол командасы Мәскәү "Спартагына" 6:1 исәбе белән оттырды.*

***Кытайда*** *әч көн генә булуына карамастан, Вологда мэры 500 төрле ашамлык кабып карарга җигешкән. Шәһәр башлыгы бары тик кыздырылган чикерткәләрдән генә баш тарткан.*

***Русиядә*** *ел саен 14000 кеше хәбәрсез югала.*

***Идел*** *елгасы үләргә күп калмаган. "Саратовские вести" гәзите хәбәр иткәнчә, Иделнең Сарытау янындагы җирендә фенол һәм нефть продуктлары мөмкин булган чикне инде 10 мәртәбә үткән.*

***Лондондагы*** *мәшһүр Британия музееннан Рим империясеннән калган алтын балдак, муенса һәм берничә борынгы таңкәне урладылар. Аларның бәясе 250 миллион фунт стерлинг белән исәпләнә. Моны безнең акчага күчереп тә маташмагыз, акылыгызга зәгыйфьлек килмәгәе.*



### Тотып карауга ни җитә

**Зур эш алдыннан халыкка чыгу Татарстан җитәкчеләренең традициясенә әверелде.** Уракка төшәр алдыннан Президент М.Шәймиев Лаеш, Балык Бистәсе һәм Питрәч районнары хуҗалыкларында булса, ЮС Рәисе Ф.Мөхәммәтшинның "командировкасы" Кама Тамагы, Тәтеш, Спасс һәм Әлки районнары аша үтә. Барысын да үз күзләре белән күрергә, тотып карарга күнеккән җитәкчеләр шул рәвешле ике куянны берьюлы тоталар - "үзләре" килү урындагыларны тәртипкә өйрәтсә, ил җитәкчеләре халык әйткән хаклыкны ишетеп кераләр.

### Байыйсылар бар әле

**Татарстанлыларга тагын акча кирәгә тора: быелның 11 августыннан исемле хосусыйлаштыру чекларын өләшү башлана.** Ләкин бу кыйммәтле кәгазьләрнең Русия ваучерыннан шактый зур аермасы бар. Беренчедән, аның сандыкта саклану вакыты аз - алган көннән башлап 2 ай, икенчедән, аны теләсә кемгә сатып җибәреп булмый. Яңа елга кадәр ул чекларга һәркем йә акцияләр, һәм дәүләт милкен сатып алырга, йә аукционнан сатып җибәрү ягын карарга тиеш була. Чеклар банк бүлекчәләрендә паспорт яки башка таныклык буенча биреләчәк.

### Тормыш күрсәткече

**Биржада доллар бәясе күтәрелү үз эшен эшләде - тагын бер "халык валютасы"ның - аракының бәясе күтәрелде.** Буюлы бер шешә "Пшеничная" өчен бер мең сум (әлбәттә, яңа акча белән) чыгарып саласы була. "Московская" һәм "Русская"ның ярты литры 908 сум (шешәсеннән башка). Хәзер аракыны итәк астыннан түгел (Казанда бу арада шулай булды), ә теләсә кайсы кибеттән һәм теләсә күпме алырга мөмкин.

### Хөкемне кем чыгара?


**БТИҮ рәисе Зиннур Әһлиуллин эшен тикшерү тәмамланды.** Татар милли хәрәкәте җитәкчесе Русия Җинаять кодексының 218 маддәсе буенча гаепләнә (законсыз рәвештә корал йөртү, саклау, алу, әзерләү яки корал һәм хәрби припаслар сату). Хөкемне Казанның Идел буе районы халык суды чыгарачак.

# БОЛГАР МАНАРАСЫННАН БЕР МАНЗАРА




*...Изге Болгар җире. Бу тарихи мәркәзебезне үзебезнең халыкка да, башка халыкларга да таныту хакында күптән хыяллана идек. Вакыт уза, заманалар үзгәрә һәм бүген, ниһаять, хыялыбыз тормышка ашып килә: борынгы Болгар җире туристик үзәк маршрутына керде. Аның причалына зур-зур су лайнерлары туктый. Милләттәшләребез бирегә, изге Хаҗга сәфәр кылгандай, сәҗдә кылырга, тарихыбызга әйләнеп кайтырга дип туктый. Бүтән халык вәкилләре, төрле дәүләтләрдән килгән һәм Идел өстендә ял итәргә чыккан туристлар, "бу нинди кавемнең тарихи ядкаре икән?" дип кызыксынып, Болгар баскычларыннан текә ярга күтәреләләр.*

*Әлеге изге эшне, кичәге хыялны чынбарлык итүчеләр - моннан өч еллап элек гамәлгә кергән "Болгар фонды" вәкилләре. Тарихи-архитектура тыюлыгының оешуына инде егерме дүрт ел гомер узган булса да, бу җирнең тарихи әһәмиятен күпләргә белдертү эше нәкъ менә шушы фонд эшчәнлегенә бәйле. Хәер, Болгарның бүгенгесе турында "Болгар фонды" әгъзасы үзе сөйләсен...*



Бөек Болгар дәүләтенең үзе сайлап Ислам динен кабул итүенә быел 1104 ел тулды. Дин кабул иткәннән соң Шәһри Болгар озакламый бөтендөнья мөселман мәдәниятенең иң төньяктагы үзәгенә әверелгән. Бүгенге көндә ул халкыбызның борынгы тарихын гәүдәләндергән изге истәлеге, хәтереннән мәңге җуелмас кыйбласы. Татар халкының Мәккәсе дияр идем мин аны.

Шәһри Болгарның тарихи-архитектура тыюлыгы (заповедник) җөмһүриятебезнең Спас районы үзәгеннән ерак түгел генә урнашкан. Монда Җамигъ мәчетенең нигезе, Кече манара, Кара пулат, Кызыл пулат хәрабәләре, Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәләре (мавзолей) сакланган. Тыюлыкта археологик казу эшләре вакытында табылган төрле ядкарьләр җыелган ике музей эшли. Бу изге урын Чулман тамагыннан Идел агымы белән 30 чакрымнар астарак урнашкан. Бүген дә сокланырлык корылмаларны бабаларыбыз Иделнең аръягындагы ак таш катламнарыннан кисеп алып, ташып салганнар.

Ак һәм пакь ташлар моңы. Бу моңга халкым сукмагы беркайчан да өзелмәде, горурлык катыш матәм хисләре белән сугарылды аның күңеле. Шәһри Болгарны саклау һәм торгызу омтылышы белән янучылар арасында Казан дәүләт университетының тарих, хокук, икътисад, табигатьне саклау һәм башка фәннәр өлкәсендә эшләүче бер төркем яшь укытучы-галимнәр дә бар иде. Алар алда торган максатны тормышка ашыру өчен махсус оешма төзү зарур дигән фикергә килделәр. Бу фикерне Татарстанның киң җәмәгатьчелеге, шул исәптән фән һәм иҗат зыялыларының күренекле вәкилләре дә хупладылар. Йокысыз төннәрдә киңәшеп, бәхәсләшеп, булачак оешманың планнары ачыкланды, аның уставы язылды. Һәм шулай итеп 90 нчы елның октябрендә "Болгар фонды" барлыкка килде. Казан дәүләт университеты, Диния нәзарәте, Болгар тарихи-архитектура тыюлыгы, Татарстанның Мәдәният министрлыгы, эре промышленность һәм төзү берләшмәләре, башка тармактагы аерым оешмалар һәм хәзерге Спас районы Советы аның рәсми оештыручылары булдылар. Беренче конференциядә фондның киңәш рәисе итеп КДУ профессоры, академик Индус Таһиров сайланды, идарә рәисе итеп юридик фәннәр кандидаты Фәрит Насыйбуллин расланды.

Шәһри Болгарны һәм Бөек Болгарның башка тарихи-архитектура истәлекләрен саклау һәм торгызу хөкүмәт программасына ("Көмеш ай") нигезләнгән.

"Болгар фонды" 91 нче елның язында хәйрия лотереясе үткәрде, аннан алынган табышның төп өлеше Шәһри Болгарга су юлын - фарватерны тирәнәйтүгә тотылды. Элек район үзәгенә "Метеорлар" гына килә алса, хәзер исә тыюлыкның үзенә кадәр үк зур су лайнерлары керә. Алар өчен тукталу корылмасы (причал) куелды, яр буенда заманча туристик комплекс төзелде, аннан музей-тыюлыкка яңа ясалган баскыч илтә. Нәтиҗәдә, бөтен дөнья өчен, Идел аша килеп, халкыбызның тарихи истәлеген күрү мөмкинлеге ачылды.

Үткән елның 22 июнендә Бөтендөнья татар Конгрессы кунаклары, Казаннан сигез "Метеор" белән килеп, Шәһри Болгарны зиярәт кылдылар, анда беренче тапкыр үткәрелгән Сабантуй бәйрәмендә катнаштылар. Соңрак гарәп, ислам дөньясы дин әһелләре, дәүләт эшлеклеләре һәм БДБ илләре эшкуарлары буларак Зур форумда катнашучылар да Тәүбә мәчете ачылуга багышланган тантаналардан соң Чаллыдан махсус теплоходта Болгарга килгәннәр иде. Монда намаз укылды, сугым суелды, бу ритуалда мөфти хәзрәттән башка Төркиядән һәм башка илләрдән килгән мәртәбәле кунаклар да катнаштылар. Болгарга килүчеләр күп булды үткән елда - Татарстаннан, Башкортостаннан һәм башка илләрдән. Бу елда кунаклар тагын да күбрәк булачак. Идел маршрутларындагы лайнерлардан гына да унсигез лайнер керергә тиеш монда. Июньдә берьюлы өч теплоход туктап, аларда ял итүче 600 дән артык төрле ил туристлары Шәһри Болгарны күрүдән һәм үзләренә күрсәтелгән кунакчыллыктан зур канәгатьләнү белдереп киттеләр. Төрле делегация вәкилләре дә Болгарга барырга теләк белдерәләр.


Әлбәттә, Болгар фонды үзенең эшчәнлеген, шул исәптән хәйрия, яшь талантларга төрле ярдәм күрсәтү өлкәсендә дә, халык ярдәменә таянып башкара. Бүгенге көндә ул, Шәһри Болгардагы тарихи корылмаларны торгызу белән бергә, Изге Чишмәгә юлны төзекләндерү, Болгар-Суар-Билар-Чистай автомагистрален салу, дүрт "йолдыз"лы кунакханә төзеп бетерү (төзелешне Тәүбә мәчетен күтәргән Марат Бибишев җитәкчелегендәге Чаллы оешмасы алып бара), гомумән алганда, Бөек Болгарның тарихи истәлекләрен карау өчен заманча туризм инфраструктурасы булдыруны алга куя. Шул максатларга ирешү ниятеннән шушы елның көзендә хәйрия лотереясенең II нче тиражын үткәрергә җыенабыз. Бу тиражда катнашып, Сез җөмһүриятебез үсешенә өлеш кертү белән бергә, торак, җиңел автомобильләр, гаражлар, башка әйберләр һәм акчалата отышларга ия булу мөмкинлеген дә аласыз.

... Тукталышка якынлашкан теплоход палубасыннан Шәһри Болгарның тарихи истәлекләре яхшырак күренә, күңелне кузгата. Монда Җамигъ мәчете манарасын торгызу эшләре башланды, аның биеклеге 33 метр тәшкил итәчәк. Яр буен туристик комплексның шәрык стилендә ясалган зур залы һәм чатырлар бизи. Кибетләрдә сувенирлар, китаплар, көнкүреш товарлары һәм башка әйберләр сатыла. Кафе-ашханәдә мөселманча сугымланган иттән пешерелгән татар халык ашлары һәм башка ризыклар белән сыйлыйлар. Фонд оештырган махсус рейслар белән Казаннан килгән "Метеорлар" килеп туктый. Кунып калырга теләүчеләр өчен дә мөмкинлекләр тудырылган.

Изге Болгар сезне көтә, кадерле милләттәшләр!

**Әхнәф НӘФЫЙКОВ,**
**"Болгар" фонды вәкиле.**





# Хөкем гаделме?

КДУның журналистика факультеты урнашкан уникенче катка күтәрелүгә, деканат ишеге төбенә тезелешкән егет-кызларны күреп алдым. Татар журналистикасы бүлегенә укырга керүчеләрдер, мөгаен. Авыл баласы шәһәрнекеләрдән барыбер аерылып тора бит инде ул. Ә татар бүлегендә укырга күбесенчә авылныкылар килә. Әйе, аларны күрү белән: әле кайчан гына үземнең дә шулай эчке бер дулкынлану белән укырга керергә йөрүем исемә төште. Аңлыйм хәлегезне, абитуриентлар. Җитмәсә, бүген соңгы сынаулары икән. Моңарчы иҗади конкурстан тыш тагын өч имтихан бирсәләр, быел журфакка укырга керүне гадиләштергәннәр. Беренче сынау - моңарчы матбугатта басылган язмалар буенча. Аннан соң язма эш булган. Һәм менә соңгы сынау - тест сорауларына җавап бирү. Быелгы абитуриентлар белән нәкъ шул көнне танышып киттем. Инде күбесе тест сорауларына да җавап биреп чыккан. Нәтиҗәсе генә әлегә билгеле түгел. Шуңа күрә аларның билгеле бер киеренке халәттә булулары аңлашыла. Ул гына да түгел, соңгы елларда татар бүлегенә 10-11 дән артык кеше җыелмаса, быел унтугыз кеше килгән. Шуларның унбишен генә кабул итәләр. Ә ул унбишнең җидесе имтиханнардан тыш кабул ителгән инде. Алар кемнәр дисезме? "Т.Я." үткәргән конкурсның ике, "Мәгърифәт" газетасы уздырган конкурсның өч җиңүчесе һәм икесе - мәктәпне медальгә тәмамлаучы. Медалистлар белән быел әңгәмә (собеседование) генә уздырылган. Ә сынаулар аша калган унбер абитуриент уза икән. Үзем алар белән сөйләшәм, үзем күзәтәм. Өч егетләре бар икән. "Т.Я." конкурсында җиңгән Ф.Халиков белән дүртәү булалар инде. Ә калганнары, гадәттәгечә, кызлар. Карап-карап торам да, и-и баклар әле үзләре: сабыйлыктан да чыгып бетмәгәннәр. Ярый, тулай торакка урнашу өчен җан тирләрен чыгарып, студент икмәге ашап, бераз троллейбусларда кысылып йөргәч, сабыйлык алардан үзе чыгып качар.

Күбесе шигырьләр яза икән. Һәвәскәр композиторлар конкурсында катнашучы Р.Вәлиев тә бирердә. Монысы әлбәттә куанычлы. Тик белемнәре ягыннан әлләни күзгә ташланмыйлар. Кеше күзәтү кызык инде ул. Сез тикшерә икән бу дип уйламагыз. Һич юк. Алар белән үзебезнең абитуриент чагыбызны гына чагыштырам. Без дә шундый булдык микән? Әйе, кемдер чаялыгы, көләчлеге, кемдер усаллыгы, кемдер аз сүзлелеге, тыйнаклыгы белән күзгә бәрелә. Ул арада яңа танышларымны соңгы нәтиҗәләрне әйтергә чакырып алдылар. Чыкканнарын көтәргә булдым. Алар өчен борчылам. Яңа гына танышсак та, ничектер күңелгә якын үзләре. Хөкем гадел булсын иде дим. Менә үзләре дә чыгалар. Берни әйтмәсәләр дә, йөзләреннән бар да күренә. Берничәсенең күзләрендә яшь. Студентларның сайлап алынуы әйбәт күренеш. Ләкин... их, кызганыч. Бала-чактан ук газета-журналларга язып торган матур кызларны университет бусагасыннан кире бордылар. Ә мәктәпне тәмамлар алдыннан гына иҗат итә башлаган кайберләре укырга керде. Анысы, комиссиянең хөкеме дөрестер дә. Ләкин, күңел нигәдер риза түгел...

**М.БИЛАЛОВА.**

# ЭШЛӘҮЧЕ ЮК, КӨРӘШ ДӘВАМ ИТӘ

(Ахыры. Башы 12 санда.)

Коммунистлар һәм рус карагруһ шовинистларының уртаклыгы нәрсәдә? Диктатура һәм "Бүленмәс Бөек Рус Державасын" кайтарырга теләүдә. Шуның өчен бүгенге хөкүмәтне һәм власть структураларын бәреп төшерүдә. Ә инде властьны кулга алгач, анда күз күрер: "кем белән властьны уртаклашуны үзебез карарбыз"...

Асылда, кая карасаң да - кызыл флаглар. Безне мәктәптә өйрәткәннәр искә төшә: "кызыл төс ул - көрәштә түгелгән кайнар кан символы". Митингтагыларның һәр сүзендә, һәр лозунгысында, һәр хәрәкәтендә - аяусыз көрәшкә чакыру. Димәк, тагын да каһәрле көрәш, бәрелеш, тагын да кан кою? Теләсәң-теләмәсәң дә, бу "аяусыз көрәшчеләр" арасында киләчәктә түгелергә мөмкин булган кан исен сизәсең...

## Иң зур дошман кем?

Кызылларның һәм империя өчен җанын бирергә әзер "урра-патриот" шовинистларның иң күрәлмәгән дошманнары - Ельцин һәм Останкино телеүзәге. Эчләрендә кайнаган нәфрәтләрен митингта катнашучылар иң усал, кискен, үтергеч, әдәби сүзлекләрдә булмый торган сүзләр белән белдерәләр. Ул сүзләр телдә генә түгел, ә язылган лозунгларда да чагыла. Мисал өчен кайбер лозунгларны бирәм. Бу лозунгларны мин бик төгәл итеп, бозмыйча яздым. Укучылар күз алдына китерсен өчен, өстим: боларга караганда ун тапкыр кискенрәк, усалрак һәм әшәкерәк сүзләр белән язылганнарны мин монда күрсәтә алмыйм, чөнки телем бармый. Укучылар бөтен "ароматын" сизсен өчен лозунгларны үз телендә (рус телендә) бирәм.

"Ныне Кремль - сборище подлецов и дармоедов во главе с президентом. Гоните эту тварь!!!"

"России - русское правительство!"

"Долой диктатуру демлжеца и его конституцию!"

"Омоновец! Во сколько оценил президент твою готовность убивать?"

Күп кенә митингчылар СССРны кайтаруны таләп иткән лозунглар күтәргәннәр:

"Верните нам наш великий СССР!"

"Хватит клеветать на великий СССР - нашу Родину!"

Кайберләре сатира һәм сарказм белән сугарылган: "Ассенизируем Россию в кратчайший срок!" "Не позволяйте себя зомбировать!"

Уклар һәм утлар иң күп җибәрелгән мишень - Останкино телеүзәге. Бу очракта "патриот көрәшчеләр" үзләренең бөтен зәһәрлекләрен эшкә җигәләр: "Останкино - империя лжи и зла!" "Эфир - патриотам, а не предателям!" "Брешут, как Геббельс, круглые сутки!" "Останкинская башня - как змея!"

Митингта катнашучыларның иң яратмаган сүзләре - "референдум" һәм "конституция": "Рефрендумы - незаконны!" "Народ, очнись и спасай Россию! Конституцию под ельцинский фашизм не допустить!"

## Милли лозунглары

Бүген БДБ һәм Русиядә милли мәсьәлә бик катлаулы һәм кискен булганлыктан, кызылларның һәм рус милли шовинистларының карашларын ачыклыйсым килә. Ә карасаң, аны ачыклап торасы да юк, аларның карашлары шәрран-яра ап-ачык икән ләбаса! Антисемитизм бик көчле монда - яһүдләргә болар кара нәфрәт белән карыйлар: "Лишить званий и степеней иудо-сионистских подонков!"

Ә башка милләтләргә? Асылда башка милләтләргә дә шундый ук караш. Хәтта "суверенитет", "милләтләр исеме" дигән сүзләр дә аларны чыгырларыннан чыгара: "Убрать из законодательства суверенитеты, президентства, название наций и народностей!" Бу гаҗәеп лозунг тоткан ир янына килеп, аңа сорау бирәм:

- Ничек инде "убрать название наций"? Милләтләр тел булмаячакмыни? "Рус" дигән сүзне дә алып ташларгамы?

- Бөек рус милләте яшәде һәм яшәячәк! Русларны күралмаган башка милләтләр үч алуның ни икәнен үз җилкәләрендә нык татыячаклар әле! - ди ул. - Ә башка милләтләргә һәм микроскопик милләтчекләргә килгәндә, аларны сатлык милләтче лидерлары котырта. Алар - совет халкы, совет милләте, элек алар горурлык белән бу исемне йөрттеләр!

Юк инде, мондый кешегә бер нәрсә дә аңлатып булмый...

Митингчылар милләт хокукларына гына түгел, федератив килешүгә дә каршылар: "Федеративный договор - узаконенный дележ России паханами национальных мафий на сферы влияния!"

Ә соң милли мәсьәләне ничек хәл итәргә? Гениально гади итеп: "Выгнать всех инородцев из России!"

- Ничек куарга? Кая, Себергәме? ГУЛАГ утрауларынамы? - дип сорыйм мин бу лозунгны тоткан кешедән.

- Теләсә кая китсеннәр, тик Россияне бутамасыннар! - ди эче нәфрәт белән тулган "рус паториоты".

- БДБның башка 14 мөстәкыйль дәүләтләрендә 40 миллионга якын рус кешеләре яши. Әгәр да аларны да аннан куа башласалар? - дип сорыйм мин.

- Алар мөстәкыйль дәүләтләр түгел, ә СССРның кисәкләре. Без аларны кире кайтарып, СССРны торгызачакбыз! - ди ул. Аннан соң нидер исенә төшеп, өсти. - 1991 елның 17 мартында СССРдагы бөтен халыклар да "СССРны саклыйбыз!" дип тавыш бирделәр. СССРны кайтару ул - законлы эш.

- Ә ул республикалар кайтырга теләмәсә? - дип дәвам итәм мин.

- Кит, яхшылык белән кит, ычкын моннан! Провокацион сораулар бирсәң, эшең начар бетүе бар, бар кит! - ди минем "әңгәмәдәшем"...

Митингта төрле коммунистлар һәм рус карагруһ шовинистлары чыгара торган газеталар саталар: "День", "Советская Россия", "Правда", "Молния" һ.б. Ләкин башка юнәлештәге газет-журналларга митингчыларның карашы кырыс һәм каты: "Журналисты - наравне с проституцией!" дип язылган бер лозунгта...

## "Сүз ирege һәм эфир!"

Митингта катнашучылар үзләренә сүз ирегe һәм радио-телеэфир бирүне таләп итәләр.

- Менә бит сезгә митингка җыелып хөкүмәтне сүгәргә рөхсәт биргәннәр. Бу соң сүз ирегe түгелмени? Сез газета-журналлар чыгарасыз, анда теләгән нәрсәләрегезне язасыз. Коммунистлар властьта чакта алар үзләренең дошманнарына сүз ирегe бирдеме? - дип сорыйм мин.

Юк, алар белән бәхәс алып барырга мөмкин түгел. Алар аңа күнекмәгән, аны яратмыйлар. Сүгенәләр, куалар, яныйлар...

- Әгәр сез яңадан хөкүмәткә килсәгез, сездән башкача уйлаган оппозиционерларга сүз ирегe бирәчәксезме? - дип өстим мин.

Юк, моңа да сүгенүдән башка дәлилле җавап юк. Акыл, дәлилләр, логика аларга кирәкми. Асылда алар - фанатиклар.

Шулай да мин аларны аңларга телим. Ярар, Ельцин хөкүмәтен төшерделәр, дип фараз итик. Эшләп чыгаруның кимүе, бәяләрнең котырып үсүе, икътисадның таркалуы, туктаусыз инфляция иртәмесоңмы аның хөкүмәттән китүенә китерергә мөмкин. Сәяси тормышның гаҗәп болганган чоры, - теләсә нәрсә көтәргә була.

Ләкин андый очракта кемнәр килер Кремльгә? Коммунистларны? "Корыч куллы" рус шовинистларымы? Үзәктәгеләрме? Яңа демократлармы? Кемнәр? Руцкой, Вольский, Анпилов, Астафьев, Жириновский? Боровой, С.Федоровмы, әллә генерал Макашовмы? Кем?

- Властьны гына кулга алыйк, ә лидерны табарбыз! - диләр митинг ясаучылар.

Юк, минемчә, искегә кайту мөмкин түгел. Әгәр кайта икән, Россия бер вакытта да алдынгы, мул тормышлы, ирек һәм цивилизация булган илләр арасына керә алмаячак...

## Россиядә ничә компартия бар?

Минемчә, ким дигәндә алты компартия. Аларның иң активлары: Виктор Анпиловның РКРП (Российская коммунистическая рабочая партия); Нина Андрееваның ВКПБ (Сталин партиясенең исеме); Купцов һәм Зюгановның РСФСР КП (компартиясе); РПК (Российская партия коммунистов).

Асылда бу хәрәкәттә бердәмлек юк. Виктор Анпилов коммунистлары Купцов һәм Зюганов коммунистларын тетепмететәләр: "псевдокоммунисты", "антиленинский блок", "правооппортунисты", "ревизионисты", "ренегаты". "Купцов и Зюганов, - дип яза Виктор Анпилов чыгара торган газета, - стремятся пополнить галерею таких деятелей, как Бернштейн, Каутский, Зиновьев, Каменев, Бухарин"...

Нигә аларга Анпилов шулкадәр күп ут яудыра? Чөнки Купцов һәм Зюганов "поддерживают развитие парламентаризма, реформ и законопослушания...", "придерживаются веры, что социализм может иметь разные пути развития..."

Ә соң "чын", "чиста", "бозылмаган" коммунистларның төп максатлары нәрсәдә? Бүген аларның программасы нидән гыйбарәт? Әйдәгез, аларның сүзләрен һәм фикерләрен бозмас өчен, үзләренә сүз бирик. Менә иң күренекле коммунист Виктор Анпилов чыгара торган "МОЛНИЯ" газетасының 58 нче саны. Анда Россия компартиясе Үзәк Комитеты әгъзасы Теймураз Авалианиның "Идет третья мировая" дигән мәкаләсе басылган. Монда бөтен нәрсә ачык. Укучыларга бөтен "нечкәлекләре" җитсен өчен фразаларны сүзгә-сүз газетадан алам һәм үз телендә бирәм (татар укучысы русча белә ләбаса).

## "Өченче дөнья сугышы бара!"

Максат: "восстановление нашего единого государства СССР с сильной центральной властью". "Нам надо готовить народ к решительным действиям, к взятию власти". "Необходимо главное внимание направить на подготовку народных масс к революции, гражданской и национально-освободительной войне одновременно".

Аңлашылдымы, хөрмәтле укучым? Революциягә һәм сугышка хәзерләнергә кирәк! Бер үк вакытта ике сугышка - гражданнар һәм милли-азатлык сугышына! Балки эвенк, хакас яисә чукча халкының мили азатлыгы өчен сугышыргадыр? Юк, америкалылардан, немецлардан, японнардан, төрекләрдән һ.б. азат булыр өчен сугышырга! Бөек Сталинның якташы Авалиани элеккеге СССРның бөтен халыкларын революциягә, сугышка, кан коярга чакыра...

Укучыны һәм тыңлаучыны бөтенләй телсез калдыру һәм һуштан яздыру өчен кыска һәм көчле лозунг-фраза ыргыта: "Идет третья мировая война!"

Юк инде, Авалиани һәм Анпилов әфәнделәр, безнең халык көрәштән, сугыштан, кан коюдан гарык булып туйган. 75 ел буе көрәштек, сугыштык, - әле бүген дә элекке СССРның күп төбәкләрендә кан коялар. Әгәр бөтен Җир шарын алып карасак та, - кайда үзара үтереш, кан кою бара, - анда коммунистлар социализм яисә коммунизм төзү тәҗрибәсе үткәргән җирләр. Рәхим итегез: Югославия, Әфганстан, Кампучия, Сомали, Эфиопия, Ангола, Мозамбик... Ә кешеләргә тынычлык, тырыш хезмәт, муллык, азатлык һәм бәхет кирәк, алар шуңа мохтаҗ. Революциягә һәм сугышка түгел...

## "Бөек КПСС"ның кайтуы мөмкинме?

Элек Россия империясе, аннан соң СССР булган төбәкләрдә колхоз-коммуна менталитеты, "общинное сознание" кешеләргә нык кына сеңеп калган. Бу - факт. "Әгәр миндә юк икән, синдә дә булмасын". "Минем хуҗалыкта ат-сыер булмаса, күршедә дә булмаска тиеш". Менә мондый хәерчелек нигезендә тигез булу психологиясе әле бездә бетмәгән, һаман яши бирә. Әгәр таныш кеше машина алса, еш кына әйтәчәкләр: "Эшләп алган акчага машина алып булмый! Димәк, аның нindидер законсыз кереме бар, димәк, ул кайдандыр нидер урлый..." Парадокс: бөтен дөнья илләрендә эшләгән акчага машина алып була, ә бездә булмый...

Халыкның күпчелегендә сәяси һәм экономик томаналык бетмәде, әле һаман яши бирә. Күпләрдә сабыйларча өмет бар: гадел, әйбәт, көчле, сатылмый торган "юлбашчы" килеп, бай һәм матур тормыш бирсен иде...

Менә бу томаналыкны искә алсак, безнең бозылган уникаль илдә теләсә нинди вакыйгалар көтәргә мөмкин. Әгәр икътисад җимерелү дәвам итсә, тормыш түзәлмәслек авырайса, халык ачлыкка якынайса, коммунистларның активлыгы һәм саны һичшиксез артачак. Әгәр алар патша империясен торгызырга теләүче рус карагруһчылары, күп санлы дәүләт бюрократ-түрәләре, казаклар, иске караштагы хәрбиләр һәм башка оппозицион көчләр белән союз төзесәләр, аларның бергәләп властька килүләрен тесләтик иктән бөтенләй мөмкин түгел дип әйтеп булмый.

Тик, минемчә, бу мөмкинлек бик зәгыйф. Һәм алар хөкүмәткә килсәләр дә, аларның хакимият гомере кыска булыр иде. Беренчедән, халык инде үзгәрде, камчы белән кусәкне оныта бара. Икенчедән, коммунистлар властьны башкалар белән бүләргә яратмыйлар. Бик тиздән алар үзләренең "союзникларын" урыннарыннан куып чыгарырлар һәм алар белән дә көрәшә башларлар иде. Өченчедән, андый очракта бөтен дөнья илләре безгә бөтенләй аркалары белән борылырлар иде...

Ләкин 19 миллион членнан торган "Бөек КПСС" беркайчан да кире кайтмаячак, минемчә. Нигә кайтмаячак?

1. Коммунистлар идеологиясе, хәрәкәте бөтен Җир шарында сүнеп бара. "Тимер пәрдә" ачылгач, бөтен дөнья безнең ачлык һәм ялангачлыкны күрде һәм безгә охшарга теләгән кеше аз калды. Мисал: заманында бик популяр һәм күп санлы Италия компартиясе дә исемен "демократическая партия левых" дип үзгәртте. Таянырлык "социалистик лагерь" илләре дә калмады.

2. КПСС таратылгач, 19 миллион членның 98% проценты коммунист идеологиясенә ышанмаган булуы ачык күренде. Асылда алар коммунизмга ышангага түгел, ә "җылырак", файдалырак урын алу өчен партиягә кергәннәр икән ләбаса! Әнә, карагыз, бер үк партиядә нинди "төсләрдәге" кешеләр булган икән: Лигачев, Горбачев, Крючков, Ельцин, Макашов, Ал.Яковлев, Жириновский, Анпилов, Бабурин, Бурбулис, Хасбулатов, Нина Андреева, Виталий Коротич, Руцкой, Зюганов... Әгәр җентекләп карасаң, алар фикердәшләр дә, бер идея белән сугарылган көрәштәшләр дә түгел, ә сәяси һәм идеологик карашлары белән бөтенләй төрле-төрле (күп очракта капма-каршы) кешеләр бит!

3. Иң мөһиме - төрле-төрле яфрак чыгарып килә торган компартияләрнең гади халыкны үз артыннан ияртерлек позитив программасы, ышандырырлык хәрәкәт юлы юк. Ельцин хөкүмәтен сүккәндә әле аларны тыңлаучылар бар: тормыш авыраюын кем сизми?

Ләкин аларның тепле, укыган, акыллы, киң карашлы кешеләрне ышандырырлык уй-фикерләре, программалары юк. "Корыч куллы" хөкүмәт төзү, тагын бер мәртәбә коралланy, ирекле сәүдәне тыю, тимер дисциплина урнаштыру, крестьяннарга үз җирләрен бирмәү - программа түгел. Бу - тагын да бер табактан ашый торган коммунага чакыру бит! Ә үзләре өчен иң зур теләк һәм максат - властька менү...

...Коралланyны, көрәшүне, революция ясауны, сугышуны ташлап, тыныч кына тырышып эшли башларлармы соң берәр вакыт бу кешеләр?..

Вахит ЮНЫС

Маскәү.



- Улым, әтиең баскычтан мәтәлеп төшкәндә нәрсәләр кычкырды?
- Әшәке сүзләрне төшереп калдырып әйтергәме?
- Әлбәттә.
- Ул чагында бер нәрсә дә кычкырмады.

* * *

Бер ир кеше яр буенда балык тотып утыра. Янәшәсендә эте дә бар. Болар янына ат килеп туктый.
- Нәрсә, абзый, чиртәме?
- Бар әле, юлыңда бул, синең кайгың юк!
Ат китеп бара. Ул китеп бераз вакыт узгач, балыкчы корт чаккандай сикереп тора.
- Могҗиза! Ат кешечә сөйләшә!!! Ә син, эт, ник йоклап утырасың!

- Мин үзем дә ишеткәч исем-акылымны җуйдым.

* * *

"Нью-Йорк - Мәскәү" рейсын башкаручы самолет Шереметьевога утырырга әзерләнә. Стюардесса белдерү ясый:
- Каешларыгызны катырак кысыгыз - Мәскәүгә төшәбез.

* * *

Яшь кеше эшкә урнашырга килә һәм үзен директор итеп алуларын сорый.
- Сез, нәрсә, акылдан яздыгызмы? - ди аңа кадрлар бүлеге мөдире.
- Юк. Ә нәрсә, директор булып эшләр өчен ахмак булу мәҗбүримени?

* * *

- Син нигә лотерея буенча зур акча откаaныңны хатыныңнан яшерәсең?
- Лотерея билетына акча каян алдың дисә, мин нәрсә дип җавап бирермен?

* * *

Ир белән хатын Луврда йөриләр. Ире корсак асты яфрак белән генә капланган шәрә кыз скульптурасы янында катып кала.
Хатыны:
- Нәрсә терәлеп каттың, күз җиткәнен көтмисеңдер ич?



*Юк, бу тигр авызы түгел. Бу - кәньяк урыс овчаркасы. Русия Оборона министрлыгы этләр мәктәбе тота. Анда һәрвакыт 1175 дүртаяклы ил сакчылары укытыла. Уку срогы - биш ай. Биредә мина эзләүчеләр, "подрывниклар", связниклар, химиклар һәм башка белгечләр әзерләнә.*

ИТАР-ТАСС фотосы.




**Милиция** кая карый" дигән сорауга бүген "Урамдагы һәр узгынчыга." - дип җавап бирергә мөмкин. Казанның "Татарстан" кунакханәсе янында үзләрен бик иркен тоткан ике егет тәртип сакчыларын күрүгә "тәүфыйклы песи"гә әйләнеп куйлар. Мондый үзгәреш, билгеле, милиционерларны сагайта һәм алар әлеге яшь кешеләр белән кызыксынырга булалар. Егетләрнең тиз үзгәрү сәбәбе кесәдә булып чыга: Самарадан килгән кунаклардан пистолет һәм "наган" револьверы алына.

**Ә Чистайда** милиция хезмәткәрләре җирле җинаятьчел төркем башлыгының фатирыннан граната һәм мина табалар. Хуҗаның кулына богау салына.

**Түбән Кама** районының "Знамя коммунизма" совхозы конторасындагы тимер тартмадан 2500 патрон белән бергә 86 мең сум акча, 10 шешә аракы һәм юбилей уңаеннан чыгарылган 43 тимер берлек акча юкка чыга.

**Шәп** итеп киенгән һәр чит ил кешесенең кесәсе доллар белән шыплап тулган дип уйлаучылар нык ялгышалар. Зеленодол районы янында Идел аша йөрүче паромда Польша гражданинына пистолет терәүчеләр моңа үз күзләре белән күреп ышаналар. Ару гына киенгән чит ил кешесеннән нибары биш мең сум урыс рубле табыла.

**Казанга** Октябрь районыннан эш белән килгән слесарьның кесәсендә дә полякныкыннан күп акча булмый. Ләкин яшь рэкетчылар аннан 100 мең сум акча таләп итканнәр. Болай гына котылып булмаслыгын аңлаган кунак милициягә мөрәҗәгать итә һәм тегеләрне "җылы килеш" кулга алалар.

**Чаллыда** Мәскәүдән килгән кунакның да күңелен калдыралар. "Бигеш" аэропортының бәдрәфендә билгесез кешеләр аның йөзенә газ җибәрәләр һәм кесәсеннән 240 мең сум акчасын алалар

**Ә шул ук Чаллыда** 27 яшьлек беркайда да эшләмәүче бер бәндә (ир-ат дигән сүзне кулланасы килми) үз сөяркәсенең өеннән 1.5 миллион сумлык "бирнә" белән юкка чыгарга уйлаган.

*Игътибар: яңа рубрика *Игътибар: яңа рубрика *

KNOW-HOW




## Җиләк вакыты

***Җәйнең иң гүзәл чагы. Яшеллек, җылылык, эссе көннәре белән генә түгел, муллык белән дә тулган чоры. Бакчаларда җиләк пешә. Берсе артыннан икенчесе өлгереп кенә тора. Җиләк, карлыган, чия... Кышка кайнатмалар әзерләргә, кышкы салкында җәйне искә төшереп чәй эчәргә кем теләмәс. Кайнатмаларның кайбер рецептлары белән таныштырабыз***

Кайнатма яхшы сыйфатлы булсын дисәгез, чималның да иң әйбәт сыйфатлысын алыгыз. Сайлап алынган җиләкләрне яхшылап юыгыз, сабак, яфрак һәм башка чүпләрдән арындырыгыз. Күпчелек җиләк-җимешне кайнатыр алдыннан кайнар суга салып алырга кирәк: Ә ул суны ширбәт (сироп) ясау өчен файдаланырга.

### Кара карлыганнан кайнатма

Кайнар суга салып алганнан соң карлыганны кайнап торган ширбәткә салырга (1 килограмм карлыганга 250 грамм су, 1.5 килограмм шикәр кирәк). Өстен ябып биш минут кайнатырга. Кайнатканда кәстрүлне селкеткәләп алырга. Шуның белән кайнатма әзер. Аны чиста банкаларга салып, капкачлап салкынча урынга куярга. Мондый кайнатма сыйфаты ягыннан бик яхшы санала, анда биологик яктан актив матдәләр, бигрәк тә С витамины күбрәк саклана.

### Икенче ысул

Юылган карлыганны иләккә яки тишекле чүмечкә салып, суын саркытырга. Аннары кайнап торган ширбәткә салырга, 5 минут кайнатырга. Мондый төр кайнатма өчен 1 килограмм шикәргә 600 грамм шикәр комы, 185 грамм су алына. Әзер кайнатманың өстен ябып, капкач өстеннән тастымал белән төрәләр. Аннары пар чыкмасын өчен одеял ябалар.

Шушындый "мунча"да кайнатманы 45 минут тоталар. Аннары банкаларга тутырып капкачлыйлар.

Бу ысул белән ясалган кайнатмада шулай ук бөтен төр файдалы матдәләр саклана.

### Кара карлыганны табигый хәлендә саклау

Яхшы өлгергән әле генә җыелган, әмма изелмәгән карлыганны кайнаган су белән юып киптерелгән шешәләргә тутырып, бөкеләргә, шпагат белән бәйләп, бөкене сумала белән катырырга яки сургычларга. Шешә урынына калай капкачлы пыяла банка да ярый. Мондый карлыганны суыткычта сакларга.

### Кура җиләк кайнатмасы

Әле генә җыелган кура җиләген юып тормасаң да ярый. Базардан алганны юып саркытырга. Әзер җиләкне (1 кг җиләккә 1.5 кг. шикәр комы, 500 грамм су исәбеннән) ширбәткә салып 5 сәгать тотарга. Аннары талгын утта кайнатырга. Кура җиләген артык озак кайнатырга ярамый, юкса төсен үзгәртә.

### Кура җиләгеннән компот

Чистартып сайланган җиләкләрне банка муенына кадәр тутырырга, өстенә кайнар ширбәт салырга. Банкаларны 40-45 градуслы су салынган кәстрүлгә утыртырга һәм шул килеш 10-15 минут (банка зурлыгына карап) тотарга. Аннары капкачларга.

### Күп җимешле чия кайнатмасы

1.5 килограмм чияне яхшылап юып, өстенә 1 килограмм шикәр комы салырга һәм шул килеш 6-7 сәгать тотарга. Кофе чынаягы белән бер чынаяк су салырга. Әкрен утта кайнатырга, утны көчәйтә барырга. Ширбәт куера төшкәч, 0.5 литрлы банка белән бер банка глюкоза салырга. Уттан алыр алдыннан 1 чәй кашыгы шәраб кислотасы салырга.


**Организация реализует со складов в Казани:**

1. Дома из срубов (6х6) укомплектованные пиломатериалами хвойных пород: пол, потолок, матрица, фронтоны стропилы, обрешетка. Цена - 1250 000 руб.
2. Доски необрезные 25 мм и 50 мм хвойные (6 м). Цена - 29,5 тыс.руб. за кубометр.
3. Доски обрезные хвойные 25 и 50 мм. Цена - 40 тысяч за кубометр.
4. Брус (150х150) (6 м) хвойный. Цена - 42 тысячи за кубометр.
5. Подтоварник хвойный. Цена - 12 тысяч за кубометр.
6. Доски необрезные, липа - 20 тысяч за кубометр.
7. Доски обрезные, липа - 30 тысяч за кубометр.
8. Смола хвойная (живица). Цена договорная.
9. Липа круглая (пиловочник) - 12.5 тысяч за кубометр.

**Телефон для справок: 57-92-11.**

**Оешма Казандагы складтан сата:**

*- ИЭ 1505 Э һәм ИЭ 1211 Э маркалы бәрмәле-әйләнмәле электр бораулары;*

*- кальций карбиды;*

*- ГАЗ-3507. ГАЗ-33073. ГАЗ-31029 автомашиналары.*

*Оешма, шулай ук, КамАЗ автомобильләре һәм аларның запас частьлары, тепловозлар, лифтлар, башка промышленность җиһазлары өчен кирәк булган электр двигательләре белән тәэмин итә.*

**Казандагы телефон: 57-01-22.**


# Котлыйбыз!

***Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 3000 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк. Хатларыгызны бер ай алдан җибәрүегезне сорыйбыз.***

* * *

Буа районы, Нурвахит авылында яшәүче кадерле әниебез Бану Хәйруллинага июль аенда 55 яшь тулды. Без аны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз. Кадерле әниебез! Сиңа саулык-сәламәтлек, озын гомер, бәхет-шатлыклар телибез. Кызларыңның һәм кияүләреңнең рәхәтен күреп яшә.

**Кызларың, кияүең.**

* * *

Чистай районы, Татар Баганалысы авылында яшәүче әниебез Минниса Төхфәтуллинага июль аенда 55 яшь тулды. Чәчәкле җәй аенда туган кадерле әниебезгә исәнлек-саулык, тынычлык белән тагын да күп чәчәкле җәйләр күрергә насыйп булсын.

Иң изге теләкләр белән әтиебез һәм барлык балалары исеменнән, кызы Фиалка.

* * *

Актаныш районы, Иске Сафар авылында яшәүче кадерле әткәебез Хатыйп Салихҗановка июль аенда 60 яшь, әнкәебез Нәҗибәгә 59 яшь тулды. Хөрмәткә лаеклы кадерле әткәй һәм әнкәй! Сезне чын күңелдән бәйрәмегез белән котлыйбыз, корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, күп шатлыклы тыныч тормыш, балаларыгызның игелеген күреп, борчу-хәсрәтсез тигез гомер кичерүегезне телибез.

**Иң изге теләкләр белән: кызыгыз, киявегез, оныкларыгыз.**

* * *

Ульяновск өлкәсе, Мәләкәс районы, Нәрәү авылында яшәүче әниебез Гөлчәрә Мөхәммәтиевага июль аенда 59 яшь тулды. Кадерле әниебез! Синс туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз. Озын гомер бирсен ходай сиңа, сызламасын аяк-кулларың, күзләреңнең нуры сүнмәсен. Кайгы-хәсрәт күрмичә, саусәламәт яшә.

Кызы, уллары, кияве, киленнәре һәм оныклары исеменнән: улы Рафиц.

* * *

Лениногорск районы, Яңа Иштирәк авылында яшәүче әтиебез Хәйбрахман Борһанов һәм әниебез Мөкаррәмәне 70 яшь, ә бергә гомер итә башлауларына 40 ел тулу уңае белән чын күңелдән котлыйбыз. Йомшак күңелле әниебезгә, олы йөрәкле әтиебезгә рәхмәтебез чиксез зур. Кадерле әти-әни! Сезгә озын, тигез гомер, исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, кайгы-хәсрәтсез куанычлы көннәр телибез.

Иң изге теләкләр белән: балаларыгыз.





Баш мөхәррир урынбасары
Миңнәзыйм СӘФӘРОВ
(53-07-52)

ЯЗЫГЫЗ:
420066. Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип, реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар: Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, редакциянең хезмәт коллективы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 268-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга.

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

***Редакциянең исәп-хисап счеты:***
***Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005***
***Индекс - 54121***
***Тираж - 203620***

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе.

Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды.

Заказ 6123